# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«19» февраль 2015 ел № 35/5

**Тукай муниципаль районы Советы каршында Иҗтимагый яшьләр парламенты төзү турында**

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның «ТР муниципаль берәмлекләренең закон чыгару органнары каршында иҗтимагый яшьләр парламентларын формалаштыру турында» 2014 елның 27 декабрендәге ПР-344 номерлы күрсәтмәсе нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Районның актив яшьләре вәкилләре арасыннан Тукай муниципаль районы Советы каршында Иҗтимагый яшьләр парламенты төзергә.

2. Тукай муниципаль районы Советы каршында Иҗтимагый яшьләр парламенты турында нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев